*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Риваятьләр турында исеңә төшер. Аларның үзенчәлекләрен барлап яз, мисаллар китер. (7 балл)**

**2. Рәсемне кара. Ул кайсы әсәргә карата ясалган? Әсәрнең исемен, авторын яз, әсәр геройларын ата. (6 балл)**



**3. Әсәрләрнең авторын, жанрын яз. (6 балл)**

а) «Алсу» ______________________ ____________________

ә) «Монда тудык, монда үстек» _____________________ ___________________

б) «Матурлык» _______________________ ____________________

**4. Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгелә. (10 балл)**

Кошлар моңы уятадыр сине,
Челтәр пәрдәләрне күтәреп,
Язгы таңны күзлисеңдер ялгыз
Чәчәк аткан гөлләр үтәли.

Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман, кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман
Сынып беткән, изрәп тапталган,
Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән тапланган.

**5. Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? Бу шагыйрь турында өч фактны искә төшереп яз. (6 балл)**



1) ___________________________
2) ___________________________
3) ___________________________

**6. Илнең күрке – тынычлык, диләр. Ничек уйлыйсың, бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (10 балл)**